| | |
|---|---|
| КОМИТЕТ<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН<br>ПО ОХРАНЕ ОБЪЕКТОВ<br>КУЛЬТУРНОГО НАСЛЕДИЯ | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ МӘДӘНИ<br>МИРАС ОБЪЕКТЛАРЫН<br>САКЛАУ КОМИТЕТЫ |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

14.11.2018 № 48

г. Казань

Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетында башкарган вакытта дәүләт гражданнар хезмәткәрләре үзләренең табышлары, чыгымнары, милке һәм милек рәвешендәге бурычлары, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының табышы, чыгымнары, милке һәм милек рәвешендәге бурычлары турындагы мәгълүматны тәкъдим итәргә тиешле, вазифалары коррупция рисклары белән бәйле булган дәүләт гражданнар хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында

2004 елның 27 июлендә кабул ителгән “Россия Федерациясендә дәүләт гражданнар хезмәте турында”гы 79-ФЗнчы Федераль закон, 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында”гы 273-ФЗ Федераль законы 2003 елның 16 гыйнварындагы “Татарстан Республикасында Дәүләт гражданнар хезмәте турында”гы 3-ЗРТ законы, Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге “Башкарган вакытта дәүләт гражданнар хезмәткәрләре үзләренең табышлары, чыгымнары, милке һәм милек рәвешендәге бурычлары, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының табышы, чыгымнары, милке һәм милек рәвешендәге бурычлары турындагы мәгълүматны тәкъдим итәргә тиешле, вазифалары коррупция рисклары белән бәйле булган дәүләт гражданнар хезмәте вазифалары исемлеген раслау турында”гы Указы, Татарстан Республикасы Президентының 2009 елның 30 декабрендәге “Татарстан Ресрубликасы дәүләт гражданнар хезмәте вазифаларына дәгъва итүче гражданнарның табышлары, милке һәм милек рәвешендәге бурычлары турындагы мәгълүматларны тәкъдим итүе, шулай ук Татарстан Республикасы дәүләт гражданнар хезмәткәрләренең табышлары, чыгымнары, милке һәм милек рәвешендәге бурычлары турындагы белешмәләр бирүе турында”гы УП-702нче Указы нигезендә, БОЕРАМ:

1. Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетында (алга таба - комитет) башкарган вакытта дәүләт гражданнар хезмәткәрләре үзләренең табышлары, чыгымнары, милке һәм милек рәвешендәге бурычлары, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының табышы, чыгымнары,

милке һәм милек рәвешендәге бурычлары турындагы мәгълүматны тәкъдим итәргә тиешле, вазифалары коррупция рисклары белән бәйле булган дәүләт гражданнар хезмәте вазифалары исемлеген (алга таба – Вазифалар исемлеге) расларга.

2. Вазифалар исемлегенә түбәндәгеләрне күздә тоткан вазифаи бурычларны үтәүче вазифалар керүне расларга:

даими, вакытлыча яки махсус вәкаләтләр буенча хакимият вәкиле яки оештыру-бүлү яки административ-хуҗалык функцияләрен башкару;

гражданнар һәм оешмаларга дәүләт хезмәтләрен кертү;

бюджет ассигнованиеләрен бүлү турындагы карарлар әзерәү һәм кабул итү;

контроль һәм күзәтү чараларын тормышка ашыру;

дәүләү милке белән идарә итү;

дәүләт сатып алуларын башкару;

матди-техник ресурсларны саклау һәм бүлү.

3. Хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлеге җитәкчесенә: Вазифалар исемлегенә кертелгән вазифаларны биләүче дәүләт гражданнар хезмәткәрләрен бу боерык белән таныштырырга;

Вазифалар исемлегенә кергән вазифаларны биләүче дәүләт гражданнар хезмәткәрләренә 2008 елның 25 декабрендәге “Коррупциягә каршы көрәш турында”гы 273-ФЗ Федераль законның 12 маддәсе белә каралган бурычларны аңлатырга.

4. Боерык үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Рәис И.Н. Гущин

Татарстан Республикасы
мәдәни мирас объектларын
саклау комитеты рәисенең
14.11.2018 № 48
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы мәдәни мирас объектларын саклау комитетында башкарган вакытта дәүләт гражданнар хезмәткәрләре үзләренең табышлары, чыгымнары, милке һәм милек рәвешендәге бурычлары, хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының табышы, чыгымнары, милке һәм милек рәвешендәге бурычлары турындагы мәгълүматны тәкъдим итәргә тиешле, вазифалары коррупция рисклары белән бәйле булган дәүләт гражданнар хезмәте вазифалары исемлеге

1. Югары вазифалар төркемендә "җитәкчеләр" категориясендәге Татарстан Республикасы дәүләт гражданнар хезмәте вазифалары:

Комитет рәисе.

2. Төп вазифалар төркемендә "җитәкчеләр" категориясендәге Татарстан Республикасы дәүләт гражданнар хезмәте вазифалары:

Комитет рәисе урынбасары.

3. Әйдәп баручы вазифалар төркемендә "җитәкчеләр" категориясендәге Татарстан Республикасы дәүләт гражданнар хезмәте вазифалары:

хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлеге башлыгы;

дәүләт күзәтчелеге (контроле) һәм суд-административ тәҗрибәсе бүлеге башлыгы;

мәдәни мирас объектларын саклау бүлеге башлагы;

археология һәм мәдәни мирас объектларын исәпкә алу бүлеге башлыгы;

администраторлык һәм бухгалтерлык исәбе бүлеге башлыгы;

шәһәр төзелеше эшчәнлеге секторы мөдире.

4. Әйдәп баручы вазифалар төркемендә "белгечләр" категориясендәге Татарстан Республикасы дәүләт гражданнар хезмәте вазифалары:

хокукый, оештыру һәм кадрлар эше бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

дәүләт күзәтчелеге (контроле) һәм суд-административ тәҗрибәсе бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

мәдәни мирас объектларын саклау бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

археология һәм мәдәни мирас объектларын исәпкә алу бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе;

шәһәр төзелеше эшчәнлеге секторының әйдәп баручы киңәшчесе;

5. “Тәэмин итүче белгечләр” категориясендәге Татарстан Республикасы дәүләт гражданнар хезмәте вазифалары:

дәүләт күзәтчелеге (контроле) һәм суд-административ тәҗрибәсе бүлегенең әйдәп баручы белгече;

мәдәни мирас объектларын саклау бүлегенең әйдәп баручы белгече.